**ГЛАВА ВОЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ВОЙКИНО АВЫЛ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**02.12.2021** с. Войкино **19**

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Войкино авыл җирлегенең Пановка авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Войкино авыл җирлеге Уставы нигезендә

**карар бирәм:**

1. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Войкино авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Войкино авыл җирлегенең Пановка авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 17 декабренә 14:00 сәгатькә билгеләргә.

Җыенны үткәрү урыны итеп түбәндәге адрес буенча урнашкан кибет бинасын билгеләргә: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Пановка ав., Октябрь ур., 7 й.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Войкино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә сез, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- кышкы һәм җәйге чорда торак пунктларның юлларын төзекләндерү;
- су белән тәэмин итү челтәрләрен карап тоту;
- торак пунктларда урамнарны яктырту;

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, Войкино авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

ӘЙЕ   ЮК».

4. Әлеге карарны Войкино авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Войкино авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Войкино авыл җирлеге башлыгы** **Н.П. Шәбетдинова**